КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 март г.Казань № 195

2021 елга ачык өстенлекләр
реестрын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокук актларын кабул иткәндә һәм тормышка ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карарын тормышка ашыру максатларында, 2020 елда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елга ачык өстенлекләр реестрын (алга таба – Реестр) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру чараларын Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләнә торган дәүләт программаларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук боерык белән аларны тормышка ашыру мониторингын тикшерүдә тоту буенча җаваплы затларны билгеләргә;

2021 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, ачык өстенлектәге төп мәсьәләләр исемлеге яктылыгында Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру буенча үткәрелгән эш турындагы мәгълүматны «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә кертергә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Татарстан Республикасының кызыксынучы башкарма хакимият органнары белән берлектә, Реестрда күрсәтелгән ачык өстенлекләрне тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эше барышын һәм нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртып торуны тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 март, 195 нче
карары белән расланды

2021 елга ачык өстенлекләр реестры

| Т/с | Өстенлек исеме | Өстенлекне билгеләгән халык өлеше, процент | Социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча формалаштырылган төп проблемалар исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Бәяләр һәм тарифлар үсүне тыеп тору, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын яхшырту | 54,4 | туклану продуктларына һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләренә чыгымнар югары дәрәҗәдә булу;<br>товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәяләре һәм сыйфаты бер-берсе белән туры килмәү;<br>түләү документының бердәм формасын раслый торган норматив хокукый акт булмауга бәйле рәвештә, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр формалаштыру ачык булмау;<br>торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре эшчәнлегенә нәтиҗәле контроль булмау |
| 2. | Халыкның керемнәре дәрәҗәсен (эш хакларын, пенсияләрне, пособиеләрне) күтәрү | 50,1 | эш хаклары, пенсияләр һәм пособиеләр түбән дәрәҗәдә булу; |
| 3. | Ришвәтчелеккә һәм коррупциягә каршы тору | 38,4 | коррупцияне кисәтү буенча эшләр җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмау;<br>гражданнарның хокукый культурасы түбән булу;<br>ришвәтчелеккә җәза бирү системасы тиешле дәрәҗәдә каты булмау |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Эшсезлек дәрәҗәсен киметү | 26,7 | яңа булдырыла торган эш урыннарының саны шактый аз булу;<br>тәкъдим ителә торган эш урыннары еш кына түбән эш хакы белән характерлана;<br>белем бирү оешмалары практик юнәлешле программаларны һәм технологияләрне аз куллана;<br>һөнәри белем бирү оешмаларында бюджет акчасы хисабыннан белем алучылар эш бирүчеләргә беркетелмиләр;<br>эшмәкәрлекне үстерү өчен уңай шартлар җитәрлек дәрәҗәдә булмау;<br>аерым категорияләр буенча эшсезлек буенча пособиеләрне хезмәт өчен түләүнең минималь күләме белән чагыштырырлык булу, бу хезмәт эшчәнлегенә мотивацияне киметә |
| 5. | Яңа коронавирус йогышлы авыруы (2019- nCoV) таралуга каршы чара күрү | 25,7 | вируслы һәм йогышлы авыруларны профилактикалау чараларын үз вакытында кабул итү |